| | |
|---|---|
| **ГЛАВА ТУРАЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МЕНДЕЛЕЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МЕНДЕЛЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ТУРАЙ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ** |

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

№ 12 01.11.2025 ел

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Турай авыл җирлегенең Турай торак пунктында 2026 елда гражданнарның үзара салым акчаларын кертү буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Турай авыл җирлеге Уставының 22 ст. нигезендә Менделеевск муниципаль районы Турай авыл җирлеге башлыгы
КАРАР БИРӘ:

1.2025 елның 14 ноябре 13.00 сәг. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Турай авыл җирлегенең Турай авылында  2026 елда гражданнарның үзара салым акчаларын кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын билгеләргә.
2. 2025 елның 14 ноябре 15.00 сәг. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Турай авыл җирлегенең Турай авылында  2026 елда гражданнарның үзара салым акчаларын кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын билгеләргә.

3. 2025 елның 14 ноябре 16.00 сәг. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Турай авыл җирлегенең Турай авылында  2026 елда гражданнарның үзара салым акчаларын кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының өченче этабын билгеләргә.

4. 2025 елның 14 ноябре 17.00 сәг. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Турай авыл җирлегенең Турай авылында 2026 елда гражданнарның үзара салым акчаларын кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының дүртенче этабын билгеләргә.

Гражданнар җыены уздыру урыны итеп Турай авылы, Үзәк урам, 11А йорт адресы буенча урнашкан Турай авыл мәдәният йортын билгеләргә.

Турай авылында яшәүчеләр исемлеген җыен этапларына бүлүне территориаль билге буенча түбәндәге тәртиптә башкарырга:

Беренче этап: Кама урамы, 1-4 йортлар, Яңа урам, 1-3 йортлар, Яшьләр урамы, 8,10,21 йортлар, Окольная урамы, 1-37 йортлар.

Икенче этап: Овражная урамы, 1-37 йортлар, Совет урамы, 1-33 йортлар

Өченче этап: Үзәк урам, 1-44 йортлар, Крайняя урамы, 1-33 йортлар

Дүртенче этап: Тынычлык урамы, 1-18 йортлар, Мәктәп урамы, 1-12 йортлар.

5. Гражданнар җыенында түбәндәге сорауны расларга:

“2026 елда үзара салым акчаларын Менделеевск муниципаль районы Турай авыл җирлегенең Турай авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә, ә тыл ветераннарын, югары һәм урта уку йортларының көндезге бүлегендә укучы студентларны, Россия Армиясенә сроклы хезмәткә чакырылган гражданнарны, махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзаларын азат итеп, кертергә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге ихтыяҗларга юнәлтергә Сез ризамы?”

1) Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (кышкы чорда юлларны кардан чистарту (шартнамә буенча эшләр өчен түләү)

2) янгын куркынычсызлыгының беренчел чаралары белән тәэмин итү (2 (ике) данә янгын сүндерү гидрантларын сатып алу, Турай торак пункты урамнары буйлап янгын сүндерү гидрантларын урнаштыру)

3) торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Турай авылы торак пунктында урам юлларын каплау өчен вак таш сатып алу , вак ташны тигезләү буенча транспорт хезмәтләре күрсәтү)

4) урамнарның тышкы яктырту челтәрләрен ремонтлау (яктырткычлар сатып алу)

5) торак пункт территориясен төзекләндерү (Турай торак пунктында ботакларны тураклау өчен ваклагыч сатып алу)

«РИЗА» «КАРШЫ»

3. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru  һәм www Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында http:///mendsleevsk.tatarstan.ru  “Турай авыл җирлеге” бүлегендә бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карар халыкка игълан ителгән көненнән үз көченә керә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районы
Турай  авыл җирлеге башлыгы ____________ А.Т. Нуриев
(имза) (имзаны киңәйтү)